**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4014**
**15.06.2021**

Башкарма комитетның «Гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннар бирүгә мохтаҗлар дип тану максатында, аларның кеременең һәм мөлкәт бәясенең максималь күләмен раслау турында» 2021 елның 29 гыйнварындагы 540 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннар бирүгә мохтаҗлар дип тану максатында, аларның кеременең һәм мөлкәт бәясенең максималь күләмен раслау турында» 2021 елның 29 гыйнварындагы 540 номерлы карарына, 1 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«1) гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килүче керемнең чик кыйммәтенең күләме:

- ялгыз яшәүче граждан өчен – 22 269 сум 20 тиен;
- ике кешедән торган гаилә өчен – 22 269 сум 20 тиен;
- өч һәм аннан күбрәк кешедән торган гаилә өчен – 22 269 сум 20 тиен;».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары И.З. Исхаковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов